«РАСЛЫЙМ»

Татарстан Республикасы
«Лениногорск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең
"Үзәкләштерелгән китапханәләр челтәре"
муниципаль бюджет учреждениесе директоры
Г.М. Хәсәнова

«Централизованная библиотечная система»

# Г. Тукай исемендәге Үзәк китапханәнең

# электрон уку залы турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Электрон уку залы (ЭУЗ)- ГТукай исемендәге Үзәк китапханәнең уку залы заманча мәгълүмат технологияләре нигезендә, китапханәдә электрон ресурслар кулланып эш нәтиҗәлелеген арттыру өчен төзелгән структур бүлекчә.

1.2. Китапханәнең ЭУЗ да компьютерда эшләү күнекмәләре булган теләсә кайсы кулланучы файдалана ала. Компьютерда эшләү күнекмәләре булмаган кулланучыга мөстәкыйль эшләргә рөхсәт ителми. Бу очракта китапханәче ярдәме күрсәтә.

1.3.Китапханәче интернет челтәре ресурсларына үтеп керү яисә чикләү хокукы бирә.

1.4.Китапханә интернет челтәрендәге мәгълүматның дөреслеге яисә сыйфаты өчен җаваплы түгел.

## 2. Эш тәртибе

2.1. Г.Тукай исемендәге Үзәк китапханәнең ЭУЗ да кулланучыларга хезмәт күрсәтү китапханәнең уку залында язылганнан соң, бердәм уку билетын (ЕЧБ) рәсмиләштереп kitap.tatar.ru порталының шәхси кабинетына логин һәм парольне алып, бушлай Wi-fi.ru порталын ачып, ЭУЗ куллану кагыйдәләре турындагы нигезләмә белән танышканнан соң башкарыла.

2.2. 8 яшькә кадәрге балаларга компьютер һәм интернет челтәре ресурсларыннан мөстәкыйль файдалану рөхсәт ителми. Сораулар бары тик китапханә хезмәткәрләре аша гына башкарыла.

2.3. Кулланучылар интернет ресурслар белән көненә бер сәгатьтән артык файдалана алмый. Өстәмә вакыт буш урыннар булган очракта гына бирелә.

2.4.Кулланучы тарафыннан электрон уку залы белән файдалану кагыйдәләре бозылган очракта, китапханәче кулланучыны залдан чыгарырга хокуклы. Хокук бозулар янәдән кабатлана икән кулланучыны китапханәче файдалану хокукын1 айга кадәр чикли ала.

2.5. Кулланучылар электрон уку залына матди зыян салган очракта Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылыкка тартылачак.

## 3. Кулланучының хокуклары

3.1. Интернет мәгълүмат ресурслары белән эшне белем бирү максатларында гамәлгә ашыру.

3.2. Электрон каталогларда, белешмә-хокукый системаларда, интернет челтәрендә мәгълүмат эзләү мәсьәләләре буенча белешмәне китапханә хезмәткәрләреннән алырга.

3.3. Китапханәче рөхсәте белән интернет челтәрендәге мәгълүматны, материалларны РФ законнары (РФ Гражданлык кодексының 4 өлеше) тарафыннан тыелмаган очракта күчерергә, теркәркәргә һәм сакларга.

3.4. «Үзәкләштерелгән китапханә системасы» МБУ түләүле хезмәтләр тарифы нигезендә китапханәче тарафыннан кирәкле мәгълүматны бастырырга яисә аны башка чыганакка күчерергә.

## 4. Кулланучының бурычлары

4.1. Китапханә җиһазларына һәм программа белән тәэмин итү системасына сакчыл карарга, санитария һәм куркынычсызлык кагыйдәләре техникасын үтәргә.

4.2. «Бер эш урынына - бер кулланучы» кагыйдәсен үтәргә.

4.3. Интернет челтәре ресурсларын уку процессы яисә фәнни тикшерүләр өчен кирәкле мәгълүматны эзләү өчен генә кулланырга.

4.4. Интернет челтәрендә эшләү өчен билгеләнгән вакытны үтәргә.

4.5. Җиһазларның, программалар төзексезлеге, һәм башка хокук бозулар күзәтелгән очракта , ЭУЗ хезмәткәрләренә хәбәр итәргә.

4.6.Интернет челтәреннән файдаланганда этика һәм интернетта куркынычсызлык кагыйдәләре нормаларына таянып эш итәргә.

## 5. Кулланучыга тыела

5.1. Программа һәм аппарат эшләвен бозуга китерә торган гамәлләр башкару.

5.2. Мөстәкыйль рәвештә төрле программалар урнаштыру, локаль челтәр аша башка компьютерларга керү.

5.3. Компьютерны кабызырга, сүндерергә, мөстәкыйль рәвештә тышкы һәм эчке җайланмаларны тоташтыру, хокуксыз рәвештә мәгълүматларның күчермәсен алу, файл системасына үзгәрешләр кертү.

5.4. Россия Федерациясенең 2002 елның 25 июлендәге 114номерлы -ФЗ нигезендә “Экстремистик эшчәнлеккә каршы тору турында” тыелган мәгълүматларны (шул исәптән порнографик, экстремистик һәм террористлык характердагы нормаларга туры килми торган) файдалану, интернет челтәре ресурслары аша мәгълүматларны күчереп алу һәм башкалар белән бүлешү, 2002 елның 25 июлендәге 114номерлы -ФЗ Федераль закон нигезендә милләтара көрәшне көчәйтү.

5.5. Закон нормаларын, авторлык һәм милек хокукын (Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 4 өлеше) бозу.

5.6.Компьютер мәгълүматы өлкәсендә хокук бозу, компьютер вируслары таралуга һ.б. кагылышлы гамәлләрне кылу. ("Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында" ФЗ № 149-ФЗ)

5.7. Интернет челтәре ресурсларын коммерция максатларында, шул исәптән түләүне күздә тота торган ресурслар белән файдалану (товарлар һәм хезмәт күрсәтүләрне рекламалау, сатып алу һәм сату).

5.8 Электрон почта адресын массакүләм тарату.

5.9. Ашау, эчемлекләр кабул итү һәм шулай ук өске кием белән бинага керү, телефон элемтәсе белән кулланганда кычкырып сөйләшү.

5.10. Алкоголь һәм наркотик кулланган халәттә килү.

## 6. Хисап

6.1. Китапханәчеләр интернет ресурсларнынан файдаланучыларның мәгълүматы тупланган формуляр алып бара. Анда кулланучының исеме, фамилиясе, әтисенең исеме, туган елы, паспорт мәгълүматлары, даими яки вакытлы теркәлү адресы, эш урыны, уку йорты, белеме турында белешмә һәм телефон номеры кебек мәгълүматлар бар.